РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Бирючевского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Школьная, д. 2, Азнакаевский район,
д.Бирючевка, 423307,
тел./факс (885592)6-18-81
E-mail: Bir.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Бирючевка авыл җирлеге
башкарма комитеты

Школьная ур., 2нче йорт, Азнакай районы,
Бирючевка авылы, 423307
тел./факс (885592)6-18-81
E-mail: Bir.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«08» июнь 2023 ел** **№ 4**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге территориясендә Сосновский балтырганын юкка чыгару чаралары турында

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турындагы» 23.04.2021 №276 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары нигезендә һәм чараларны оештыру максатларында, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге территориясендә Сосновский балтырганын юкка чыгару буенча, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. 1 нче кушымта нигезендә эшкәртелергә тиешле Сосновский балтырганы үскән мәйданнарны билгеләү буенча комиссия составын булдырырга һәм расларга.
2. 2023-2026 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге территориясендә Сосновский балтырганына каршы көрәш чаралар планын расларга (2 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге территориясендә Сосновский балтырганына каршы көрәш чаралары планын үтәү буенча тәкъдимнәрне расларга (3 нче кушымта).
4. Җирдән файдаланучыларга һәм барлык милек формасындагы учреждение һәм оешма җитәкчеләренә пландагы чараларны вакытында һәм тулы күләмдә башкарырга тәкъдим итәргә, аларны үткәрү буенча хисапны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Башкарма комитетына тапшырырга.
5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга:

http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык З.Г.Солтанова

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АЗНАКАЕВСКИЙ РАЙОН БИРЮЧЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ РАЙОНЫ БИРЮЧЕВКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ ОГРН 1061688044440 ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БИРЮЧЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1643008897 КПП 164301001

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Бирючевка авыл җирлеге
карарына 1 нче кушымта
2023 елның 8 июненнән №4

**Сосновский балтырганынан эшкәртелергә тиешле мәйданнарны билгеләү комиссия составы**

| | |
|---|---|
| З.Г.Солтанова | Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге башлыгы, комиссия рәисе; |
| М.Г.Нуреева | Азнакай муниципаль районының Бирючевка авыл җирлеге Советы депутаты, комиссия рәисе урынбасары; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Р.Ә.Исламов | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Азнакай муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча); |
| | «Россельхозцентр» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы вәкиле (килешү буенча) |

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Бирючевка авыл җирлеге
карарына 2 нче кушымта
2023 елның 8 июненнән №4

## 2023-2026 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Бирючевка авыл җирлеге территориясендә Сосновский балтырганына каршы көрәш чаралары планы

| № п/п | Чараның исеме | Эшләр күләме, | Чараны үтәү вакыты | Чараны уздыру нәтиҗәләре | Чараны үткәрү өчен җаваплылар |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | Сосновский балтырганы белән чүпләнгән территорияләрне тикшерү, инвентаризация | | апрельдән октябрьгә кадәр | Сосновский балтырганын таралуы турында җыелма мәгълүмат төзү | Авыл җирлеге җирле үзидарә органнары |
| 2 | Сосновский балтырганына каршы көрәш буенча кирәкле чаралар турында халык белән мәгълүмати эш | | марттан июльгә кадәр | Интернет челтәрендә муниципаль районның рәсми сайтында мәгълүматны урнаштыру | Авыл җирлеге җирле үзидарә органнары |
| 3 | Сөсновский балтырганы белән көрәшүнең механик ысулын куллану | | апрельдән октябрьгә кадәр | Сосновский балтырганының тамырларын 10-20 см тирәнлектә кисү. Сосновский балтырганының сабакларын нечкә салат фазасында (чәчәк атканчы) кисү, коры үсемлекләрне чистарту; тамыр системасын казу | Авыл җирлеге, җирле үзидарә органнары, җир участокларыннан файдаланучылар, аларның территорияларында Сосновский балтырганының үсү фактларының ачыклануы |
| 4 | Сосновский балтырган белән көрәшүнең | | майдан октябрьгә кадәр | Гербицидлар һәм (яисә) арборицидлар белән үсү | Авыл җирлеге җирле үзидарә органнары, җирдән |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | химик ысулын куллану | | | чыганакларын сиптерү;<br>Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының «Санитар кагыйдәләрне һәм нормаларны раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 3 номерлы карары нигезендә пестицидлар куллану регламентлары таләпләрен җентекләп үтәү санпин 2.1.3684-21 | файдаланучылар |

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Бирючевка авыл җирлеге
карарына 3 нче кушымта
2023 елның 8 июненнән №4

# Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге территориясендә Сосновский балтырганына каршы көрәш чаралары планын үтәү буенча тәкъдимнәр

Сосновский балтырганы (алга таба - Сосновский балтырганы) чүп үләне белән нәтиҗәле көрәшне оештыру өчен комплекслы якын килү һәм Сосновский балтырганын таралу территорияләрында барлык җаваплы затларның көчләрен туплау кирәк.

Сосновский балтырганының вегетатив үзенчәлекләрен исәпкә алып, күп тапкыр чапканда гына әлеге үсемлекне юкка чыгарып була (вегетация очен 3-5 тапкыр), нокталы яки полосалы эшкәртүләр тулысынча юк ителмәгәндә, кабат янаруга дучар була.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Сосновский балтырганы белән көрәш буенча чараларны үткәрү өчен җаваплыларга түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

1) һәр торак пункт территориясендә Сосновский балтырган үсү урыннарын картага төшерергә, Сосновский балтырган белән көрәш буенча чараларны үтәү өчен җаваплыларны, шул исәптән авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарын, җирләрне оештыруны һәм кулланучыларны күрсәтеп, әлеге мәгълүматларны картографик материалга язарга;

2) авыл җирлеге территориясендә су саклау һәм табигатьне саклау зоналарында химик көрәш чараларын куллануны чикләүне исәпкә алып, Сосновский балтырганына каршы көрәш планын эшләргә һәм расларга.

Гомуми файдаланудагы урыннарга, социаль һәм мәгариф объектларына аерым игътибар бирергә;

3) гербицидлар куллануны тыелмаган территорияләрдә Сосновский балтырганы белән көрәшү өчен химик ысулны нәтиҗәле кулланырга. Химик ысул белән эшкәртү вакыты-массакүләм үсү этабы (май ахыры-июнь башы);

4) сосновский балтырганы белән көрәш буенча чаралар үткәргәндә куркынычсызлык техникасын үтәүне тәэмин итәргә;

5) сосновский балтырганы белән көрәшү буенча чараларны, башкарылган эшләрне тапшыру-кабул итү акты белән рәсмиләштерергә.

6) авыл җирлеге территориясендә (торак пунктлар җирләре, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр, юлларны бүлеп бирү полосалары) Сосновский балтырганы үсүе зур күләмдә булганда, ведомствоара комиссия төзергә, аның составына авыл җирлеге, җирле үзидарә органнары, муниципаль район җирле үзидарә органнары, Сосновский балтырганына каршы көрәш чараларын үтәү өчен җаваплы оешмаларны һәм гражданнар вазыйфаи затларын кертергә. Комиссиядә Сосновский балтырганы белән

көрәшү вакыты, аны тулысынча юк итүгә юнәлдерелгән чаралар турында карарлар кабул ителергә тиеш;

7) җирле бюджетта Сосновский балтырганы белән көрәш буенча чараларны үтәүгә акча каралырга тиеш;

8) авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына һәр торак пунктта гражданнар җыелышын (җыеннарын) үткәрүне тәэмин итәргә, Сосновский балтырганын таралу куркынычы, аны вакытында кисү яки юк итүнең башка ысулларын куллану кирәклеге хакында белешмә тапшырырга. КФХ башлыклары, оешмалары җитәкчеләре белән, балтырган орлыкларын өлгергән чорда ук юк итү, аңлату эшләрен алып барырга. Мәгълүматны муниципаль районның рәсми сайтында урнаштырырга;

9) җаваплы затларга ведомство карамагындагы территориядә Сосновский балтырганына каршы көрәш буенча чараларның үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итәргә;

10) җирдән файдаланучыларга һәм барлык милек формасындагы учреждение һәм оешма җитәкчеләренә пландагы чараларны вакытында һәм тулы күләмдә үтәргә һәм аларны үткәрү буенча хисапны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге башкарма комитетына тапшырырга.